**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Бәркәтә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлегенең Бәркәтә торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**17 октябрь 2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлегенең Бәркәтә авылы торак пунктындагы гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Бәркәтә авыл җирлегенең Бәркәтә торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Бәркәтә авылында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, Бәркәтә авылында балалар уен мәйданчыгы территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

**- Бәркәтә авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**

- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау (Бәркәтә авылында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру).

2. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Бәркәтә авылы, Ленин урамы, 76 а йорты. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Бәркәтә авыл җирлеге башлыгы Р.М.Сибгатуллин